

Авылдан килгән тәм-томнардан авыз итәргә яратучылар, гадәттә, базарда еш кунак була. Авыл халкы очен дә башкала бәяләре кызыклы, ә бәлки, файдалы да булыр дип, без Сарансктагы «Центральный»га юнәлдек.

Иртәнге як һәм коннен салкын, жилле булуына карамастан, базар горли иде инде. Сайлау момкинлеге дә зур, бәяләр дә торле. Мәсәлән, базарнын кеpv олешендә vк яна бәрәнгенен бер килограммы 50 – 60 сум тора. Эчтәрәк - 30 сумга тәкъдим итеп торалар иде. Яшелчәсе дә, жиләк-жимеше дә, жиләкләре дә, vсентеләре дә – барысы да бар базарда. Сатучылар vз товарларын и мактыйлар, и мактыйлар. Аларда гына ин тәмлеләре, яхшылары, арзаны.

– Алып жибәр, кызым. Миндә ин арзаны. Бер майонез чиләге 200 сум тора, – ди бу.

– Әнә тегендә сатучы егет 150 сумга тәкъдим иткән иде, – дим. – Әй, алыпсатар бит ул. Ә без vзебез vстерәбез. Безнеке шәбрәк…

Бу коннәрдә базарнын топ геройлары – гомбә, дисәм, бер дә ялгышмамдыр. Светотехстрой, Химмаш районнары базарларында бигрәк кvп сатыла. Урман сыенын нинди генә торләре юк биредә. Гомбәне, башлыча, Кочкурово, Большие Березники районнарыннан жыелганнарын саталар. Ин затлы ак гомбәнен матурларын, кечерәкләрен 700 – 900 сумга саталар. Дорес, бәяләр торле, сатулашырга да момкин. Мәсәлән, 2 кг сыешлы чиләктәге бер vк торле гомбә бер кешедә бер бәя, икенчесендә

башкача булырга момкин. Шуна кvрә кvз тошкән беренче товарны сатып алганчы, ботен базарны әйләнеп, чагыштырып карап алсагыз, оттырмассыз.

Урам якта йоргәч, базарнын эчке, осте олешенә уздым. Яшелчә, жиләк-жимеш сатучылар янына тукталмыйча, ит сатучылар янына бардым.

– Кызым, ал әле итемне. Бик тәмле,- дип эндәште Ләмберә районыннан килгән апа.

Табыш кына кертми, чыгым да сорый шул базар. Мәсәлән, ит сатучыларны алыйк.

– Урын очен аена – 18,600 сум, лабораториягә 300 сум тvлибез. Бугазлау урынында ветеринар белән печать очен 700 сум бирәбез, - ди исемен әйтергә теләмәгән чибәркәй сатучы.

Сатучылары кvбесенчә олкән яшьтәге апалар булган кебек, сатып алучыларнын да кvпчелеге олкән яшьтәгеләр кебек тоелды мина.

– Еш киләм базарга. Якын да, кибеткә караганда тәмлерәк тә. Гадәттә, авыл каймагын алам. Суган, бәрәнгесен дә алгалыйм. Каражиләк белән мvк жиләген алып, катырырга куям, - диде Рәхилә ханым Исмаилова.

Сатулашыр, сайлап, карап алыр очен яхшы урын инде ул базар. Сатулаша белсән, әлбәттә. Белмәсән, vзенне дә топ башына утыртып калдырырга момкиннәр. Чонки бәяләр торле булган кебек, сатучылары да бик «шома».

Кайбер диетологлар раслаганча, ин файдалы продукт vз жирендә vстерелгән. Ә безнен жир, Аллага шокер, унышны бирә. Бу хакта район азыктолек базарлары сойли; анын топ халкы жирле яшелчә һәм жиләк-жимеш белән мәшгуль. Әлбәттә, помидор, әгәр ул vз тvтәлендә vстерелгән, Коньякныкына караганда 3 тапкыр кыйммәтрәк. Тик бу бит помидор! Мондый “vгез йорәгенен” тәме генә ни тия! Мәсәлән, килограммы очен 100 сум

сорыйлар Ельник базарында. Быел барысынын да жиләк-жимешләре булмады. Анлашылмаслык сәбәпләр аркасында, слива һәм чиянен майдагы шау килеп чәчәк атуы жиләк-жимеш китермәде. Барысы да буш тос белән очып узды. Шуна кvрә чиянен бәясе дә арзан тvгел - чиләк очен 1000 сум. Бакча грушасынын чиләген 500әр сумнан саталар. Ельник районы бакчачыларына кондәшлекне Краснослободск бистәсе халкы тәшкил итә. Суган да, сарымсак та биредә арзанрак. Хатын-кыз йодрыгы кадәр сарымсак башы очен 35әр сум. Базарда яшь бәрәнге дә бар. Әлегә чиләкнен уртача бәясе - 300 сум. Әмма бәрәнгене әле бик азлар гына казый, бәясе, уртача унышка карап, очызрак булыр, могаен. Район базарында сыер ите 380-400 сум тора.

Бал спасын элеккеге бәя белән каршы алдылар бу якларда. Ельник умартачыларына Торбеево умартачылары кондәшлек итә. Аларнын балы тәмле, хуш исле һәм ана ихтыяж зур. Умартачылар бәяне “не загибают”, бу шифалы продукт, узган елдагы кебек vк, 1 литрына уртача 500 сум сорыйлар.

Сvз унаеннан. Коньяктан алып кайтуда эшләvче эшмәкәрләргә дә рәхмәт әйтергә кирәк. Карбыз, кавын, абрикослар, нектариналар, виноград, цитрус, алмалар - кvнелен ни теләсә, бар да бар; акчан гына чыдасын! Менә шундый ул бvгенге базар хаклары.

**Наилә НАСЫРОВА**